ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Әлеге Законның 4 – 7 статьяларында, 8 статьясының 7 һәм 8 пунктларында, $8^1$ һәм $8^3$ статьяларында каралган социаль ярдәм чаралары бу Законның 2 статьясындагы 1 пунктының икенче – бишенче, унынчы – уникенче, унбишенче абзацларында күрсәтелгән гражданнарга аларның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычы булмаган очракта билгеләнә.

Күрсәтелгән бурыч социаль ярдәм чараларын билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынганда, социаль ярдәм чараларын бирү аларны билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән гамәлгә ашырыла.

Әлеге Законның $4 – 8^3$ статьяларын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 13 ноябрь
№ 68-ТРЗ